АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»
улица Батурина, д.7а, город Казань, 420111

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ
Батурин урамы, 7а, Казан шәһәре, 420111

Тел.: (843) 293-60-15, факс: (843) 293-60-22, e-mail: smo.rt@tatar.ru

_______________ №_______________
На № ___________от ______________

Главам
муниципальных районов
и городских округов
Республики Татарстан

**Уважаемые коллеги!**

Для системного развития школьных театральных студий, реализации творческого потенциала школьников и педагогов ГБУ «Татарский государственный театр драмы и комедии им.К.Тинчурина» планирует провести первый профессиональный фестиваль – конкурс для школьных и семейных театров.

Республиканский фестиваль – конкурс школьных «Театр без возраста» и семейных театров «Семейные традиции» создается для поддержки творчества как школьников, так и семей. Главная цель – объединение поколений, укрепление социальных связей в процессе сотворчества. Итогом станет гала-концерт, где объявят 3 победителей в каждом направлении (школьный и семейный). Победители получат наставников из актеров и режиссеров, а также патронаж «ТГТДиК им.К.Тинчурина».

Просим Вас довести данную информацию до сведения заинтересованных лиц Вашего района и организовать их участие в Фестивале –конкурсе.

*С уважением,*

**Председатель** **Э.С. Губайдуллин**

**Россиядә укытучы һәм остаз елы,**
**Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының 90 еллыгы уңаеннан үткәрелә торган Гаилә һәм мәктәп театрларының “Гаилә тарихы”, “Театрның яше юк” I Республика фестиваль-конкурсы нигезләмәсе**

## 1. Гомуми нигезләмә

Түбәндәге нигезләмә Гаилә һәм мәктәп театрларының “Гаилә тарихы”, “Театрның яше юк” I Республика фестиваль-конкурсының (алда Фестиваль) төп максатларын, бурычларын һәм үткәрү срокларын билгели.

Фестиваль Россиядә укытучы һәм остаз елы, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының 90 еллыгы уңаеннан Татарстан Республикасының барлык мәктәп һәм гаилә театрлары катнашында үткәрелә. Әлеге фестиваль-конкурсны уздыру Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры белән мәктәпләр арасындагы бәйләнешне ныгыта, укучыларны тәрбияләүдә уңай йогынты ясый. Моннан тыш балаларны һәм өлкәннәрне мәдәни-тарихи мираска якынайта, әдәбияткә уңай мөнәсәбәт, патриотлык һәм гражданлык хисләре уята, туган телебезгә хөрмәт тәрбияли.

## 1.Гамәлгә куючылар һәм оештыручылар:

— Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;

— Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

— ДБО “Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры”.

## 3.Фестиваль-конкурсның максаты һәм бурычлары:

— Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры белән мәктәпләр арасындагы бәйләнешне ныгыту;

— татар театры сәнгате ярдәмендә гомумбелем бирү мәктәпләрендә укучыларда һәм яшүсмерләрдә эстетик һәм рухи тәрбия үсешен активлаштыру;

— балаларны милли театр сәнгатенә, драматургия һәм әдәбиятка, музыкага һәм хореографиягә тарту;

— татар халкының мәңгелек традицияләренә, ана теленә мәхәббәт тәрбияләү;

— татар театры һәм әдәбияты  аша дөньяга карашны киңәйтү;

— патриотлык һәм гражданлык хисләре уяту.

## 3. Фестиваль-конкурста катнашучылар:

Фестиваль-конкурста Татарстан Республикасының гомумбелем бирү мәктәпләренең 5-11 нче сыйныф укучылары һәм гаилә театрлары катнаша ала.

## 4. Фестиваль-конкурсның шартлары:

Катнашучыларга таләп-тәкъдимнәр:

- Сайланган әсәр фестиваль-конкурс шартларына һәм темасына туры килергә тиеш.
- Спектакль Махсус хәрби операциягә, театрга, гаилә кыйммәтләренә, Кәрим Тинчурин һәм башка милли классик әдипләребез иҗатына бәйле, һәм башка үзегез теләгән ирекле темаларга иҗат ителә ала.
- Башкару вакытында әсәрнең темасына туры килердәй музыкаль бизәлеш кулланырга мөмкин.
- Һәр катнашучы коллективның 30 кешедән торган җанатары булу шарт.
- Катнашучылар үзләренә һәм җанатарларына кич буласы спектакльгә билет алырга тиеш (“Пушкин картасы” ярдәмендә дә мөмкин). Сатып алынган билетлар буенча Гала-концертта бүләкләр уйнатылачак.
- Гаризалар электрон элемтә аша 2023 нче елның 1 нче октябренә кадәр кабул ителә. (karimkonkurs@mail.ru )
- Мәктәп театрлары белән гаилә театрлары аерым бәяләнәчәкләр.

## 5. Фестиваль–конкурсны үткәрү вакыты һәм тәртипләре:

- Гаризалар **1 нче октябрьгә кадәр** кабул ителә.
- Җиңүчеләрне билгеләү – **2023 нче елның 1 нче октябреннән - 31 нче октябренә** кадәр барачак. Өзекләр алдан хәзерләнгән программа буенча күрсәтеләчәк. (Бер көндә 3-4 театр коллективы катнашырга мөмкин)
- Нәтиҗәләр чыгару һәм җиңүчеләрне котлау **2023 нче елның 31 нче октябрендә Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә булачак.**

### 6. Катнашучыларның чыгышларын бәяләү буенча таләпләр:

- текстны яттан белү;
- тәкъдим ителгән әсәрнең фестиваль-конкурс тематикасына туры килүе;
- чыгыш фестиваль-конкурска билгеләнгән вакыт чикләвенә сыешырга тиеш;
- сәнгатьле һәм аңлаешлы сөйләү;
- артистлык сәләте һәм эмоцияләр;
- музыкаль әсәрнең сәнгати башкарылышы;
- интонациянең чисталыгы һәм яңгыраш сыйфаты.

### 7. Жюри:

Фестиваль–конкурс кысаларында тәкъдим ителгән эшләрне Татарстан Республикасының танылган сәнгать әһелләреннән, фән һәм җәмәгать эшлекләреннән торган жюри бәяли.

Фестиваль-конкурста катнашучыларның чыгышларын бәяләү 5 баллы шкала буенча үтә. Һәр жюри әгъзасы Бәяләмә кәгазенә үз билгесен яза. Гомуми бәяләмә катнашучыларның баллар җыелмасыннан чыгып ясала. Фестиваль-конкурс җиңүчеләренә 1,2,3 нче дәрәҗәдәге **Лауреат** исемнәре бирелә. Җиңүче итеп игълан ителгән мәктәпне һәм гаиләне Кәрим Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры үз канаты астына ала (подшефство).

### 8.Фестиваль-конкурстның җиңүчеләрен бүләкләү:

Фестиваль-конкурс җиңүчеләре жюри әгъзалары тарафыннан билгеләнгән дипломнар и грамоталар белән бүләкләнә. Фестиваль–конкурска хәзерләүче укытучы яки әти-әни рәхмәт хаты белән бүләкләнә. Фестиваль-конкурс нәтиҗәләрен К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сайтында һәм социаль челтәрләрдән күреп булачак.

### 9. Мәгълүмат һәм белешмәләр:

Тел: 8(8432) 64-35-18
Эл.почта: karimkonkurs@mail.ru
Адрес: Казан шәһәре, Горький ур.,13 йорт

**Кушымта 1**

Россиядә укытучы һәм остаз елы, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының 90 еллыгы уңаеннан үткәрелә торган Татарстанның Мәктәп һәм гаилә театрлары фестивалендә катнашу өчен

гариза

| | |
|---|---|
| Номинация | |
| Белем бирү оешмасының исеме | |
| Әсәрнең тулы исеме, авторы | |
| Җитәкченең Ф.И.О., телефоны, электрон адресы | |
| Рольләрдә - Туган вакыты, тулы яше, сыйныфы | |
| Реквизит | |
| Комментарийләр | |

Сәхнәләштерелгән өзеккә бәяләмә (аннотация) җибәрүегезне сорыйбыз.

# Гаилә һәм мәктәп театрларының «Гаилә тарихы», «Театрның яше юк» I Республика

# ФЕСТИВАЛЬ-КОНКУРСЫ

Лист согласования к документу № 818 от 05.09.2023
Инициатор согласования: Батршина Ю.Н. Главный специалист отдела организационной работы и делопроизводства
Согласование инициировано: 04.09.2023 14:28

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Мизгирева Е.Г. | | Согласовано 04.09.2023 - 15:44 | - |
| 2 | Барышев А.Г. | | Согласовано 05.09.2023 - 09:58 | - |
| 3 | Губайдуллин Э.С. | | Подписано 05.09.2023 - 09:59 | - |